КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 12 август г.Казань № 647

2024 елга авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча республика адреслы программасын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2024 елга авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча республика адреслы программасын расларга.
2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 12 август, 647 нче
карары белән расланды

2024 елга гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча республика адреслы программасы

Программа паспорты

| | |
|---|---|
| Программа исеме | 2024 елга гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча республика адреслы программасы (алга таба – Программа) |
| Программаның җаваплы башкаручы | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы |
| Бюджет акчасы белән баш эш итүче | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы |
| Программаны эшләү өчен нигезләр | «Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм күрсәтү фонды турында» 2007 елның 21 июлендәге 185-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 185-ФЗ номерлы Федераль закон) |
| Программаның төп максатлары | Авария хәлендә дип билгеләнгән тәртиптә танылган авария хәлендәге күпфатирлы йортлардан гражданнарны күчерүне финанслар белән һәм оештыру ягыннан тәэмин итү (185-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә) |
| Программаның төп бурыч-лары | Гражданнарны авария хәлендә һәм яшәү өчен яраксыз дип танылган торак фондыннан күчерү (185-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә) |
| Программада катнашучы | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге |
| Программаны гамәлгә ашыру срогы | 2024 ел |
| Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганак-лары | Программаны финанслау түбәндәгеләрнең акчасы хисабына башкарыла:<br>«Территорияләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компаниясе (алга таба – Фонд) – 59 428 209,56 сум;<br>Татарстан Республикасы бюджеты – 13 206 268,79 сум;<br>Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетлары – 733 681,6 сум.<br>Программаны финанслауның гомуми күләме – 73 368 159,95 сум |

| | |
|---|---|
| Программаны тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) | Программаның төп чаралары нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары Программага теркәлгән 1 нче кушымтада китерелә.<br>Программаны үтәү буенча планлаштырыла торган күрсәткечләр Программага теркәлгән 5 нче кушымтада китерелә |

## I. Татарстан Республикасында торак фондының агымдагы торышы

Татарстан Республикасында торак фондының мәйданы 115 098,7 мең кв.метр тәшкил итә, шулардан торакның 94,2 проценты хосусый милектә (108 460,4 мең кв.метр), 4,4 проценты муниципаль милектә (5 004,1 мең кв.метр), 1,4 проценты – дәүләт милкендә (1 634,2 мең кв.метр).

Республикада 69 318,7 мең кв.метр мәйданлы 49 112 йорт, шулардан 64 161,4 мең кв.метр гомуми мәйданлы 18 079 күпфатирлы йорт (блокланган төзелешне исәпкә алмыйча) исәпләнә.

2024 елның I кварталы хәленә карата 160 күпфатирлы йорт, физик тузуына бәйле рәвештә, авария хәлендә һәм яшәүгә яраксыз дип танылды, алар таратып урнаштырыла торган 79 526 кв.метр мәйданлы 2 458 бинадан тора, аларда 5 488 кеше яши.

Муниципаль берәмлекләр тарафыннан авария хәлендәге торак фондының саны турында белешмәләр «Территорияләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компаниянең (алга таба – «ТҮФ» ГХК) автоматлаштырылган мәгълүмат системасына кертелә. Әлеге мәгълүматлар муниципалитет җитәкчесенең күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм яшәү өчен яраксыз дип тану турындагы бәяләмәләре, карау актлары, карарларының скан-күчермәләре, шулай ук фотоматериаллар белән раслана. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан әлеге мәгълүматлар, тиешле урынга барып, сайлап тикшерелә.

2024 елда Программа кысаларында дүрт күпфатирлы йортта урнашкан, таратып урнаштыра торган 574,7 кв.метр гомуми мәйданлы, 60 кеше яши торган 17 бүлмәгә урнаштыру карала, шул исәптән:

хосусый милектә – 316,7 кв.метрга 10 бүлмә;

муниципаль милектә – 258,0 кв.метрга җиде бүлмә.

## II. Проблеманың эчтәлеге һәм аны программа ысуллары белән хәл итү кирәклеген нигезләү

Татарстан Республикасында торак өлкәсенең тотрыклы эшләвенә һәм үсешенә кучү мәсьәләсен комплексны хәл итүгә юнәлдерелгән, гражданнар өчен торак сатып алу мөмкинлеген, анда имин һәм уңай яшәү шартларын тәэмин итә торган дәүләт торак сәясәте бурычларыннан берсе – ул авария хәлендәге торак фондында яшәүче гражданнарның торак шартларын яхшырту хокукларын тормышка ашыруны тәэмин итү.

Программада авария хәлендәге торак фонды астында 2017 елның 1 гыйнварыннан соң, эксплуатацияләү барышында физик тузуына бәйле рәвештә, билгеләнгән тәртиптә авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиеш дип танылган күпфатирлы йортлардагы торак урыннар җыелмасы дип аңлашыла, 2024 елда 2019 – 2023 елларга Татарстан Республикасы өчен билгеләнгән Фондның файдаланылмаган финанс ярдәме лимиты чараларының калган өлеше кысаларында аны таратып урнаштыру планлаштырыла.

Авария хәлендәге торак фондында яшәүче гражданнарның күбесе бүгенге көндә билгеләнгән таләпләргә туры килә торган торак урыннарны мөстәкыйль сатып ала алмыйлар.

Авария хәлендәге торак фондында яшәүче гражданнарны торак урыннар белән тәэмин итү проблемасын хәл итүгә муниципаль берәмлекләр бюджетларында аларны күчерү өчен җитәрлек күләмдә акча булмавы комачаулый.

Әлеге проблема Фонд һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән тиешле финанс ярдәме күрсәтелгәндә хәл ителергә мөмкин.

## III. Программаны тормышка ашыруның төп максатлары, бурычлары һәм сроклары

Программаның төп максатлары – җирле үзидарә органы тарафыннан 185-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә билгеләнгән Фонд акчасы исәбеннән финанс ярдәме күрсәтү шартларының үтәлеше тәэмин ителү шарты белән гражданнарны билгеләнгән тәртиптә авария хәлендә дип танылган авария хәлендәге күпфатирлы йортлардан күчерүне финанслар белән һәм оештыру ягыннан тәэмин итү.

Программаны тормышка ашыру кысаларында финанс ярдәме күрсәтү планлаштырыла торган гражданнарны күчерү өчен 2017 елның 1 гыйнварыннан соң билгеләнгән тәртиптә авария хәлендә дип танылган һәм, аларны эксплуатацияләү барышында физик тузу сәбәпле, сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле күпфатирлы йортлар исемлеге аңа теркәлгән 2 нче кушымтада китерелде.

Программаның төп бурычы – авария хәлендә дип танылган һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле торак фондыннан гражданнарны күчерү.

Программа 2024 елда гамәлгә ашырылачак.

Программаның гомуми бәясе 73 368 159,95 сум тәшкил итә.

Программаның төп чаралары нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары Программага теркәлгән 1 нче кушымтада китерелде.

## IV. Муниципаль берәмлекләр программасында катнашу чираты критерийлары

Программаны гамәлгә ашырганда муниципаль берәмлекләр түбәндәге шартларга туры килергә тиеш:

а) муниципаль берәмлек тарафыннан 185-ФЗ номерлы Федераль законның $20^{14}$ статьясында каралган финанс ярдәме күрсәтү шартлары үтәлү;

б) муниципаль берәмлек территориясендә 2017 елның 1 гыйнварыннан соң, эксплуатацияләү барышында физик тузу сәбәпле, авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип билгеләнгән тәртиптә танылган күпфатирлы йортлар булу;

в) муниципаль берәмлекнең күченү программасын гамәлгә ашыруга әзерлек дәрәҗәсе (күпфатирлы йортларны, торак йортларны төзүнең максатка ярашлылыгы турында карар кабул итү, күпфатирлы яисә торак йортлардан торак урыннар сатып алу өчен, шул исәптән алга таба гражданнарга социаль файдаланудагы торак урыннарына наем шартнамәләре буенча, маневр фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча бирү, торак урыннарын яшәү өчен яраклы хәлгә китерү максатларында торак базарының торышы, шулай ук торак төзелеше өчен җир кишәрлекләренең әзерлек дәрәҗәсе, муниципаль берәмлекләрнең милек хокукындагы буш (кеше яшәмәгән) торак урыннар булу, комплекслы үстерү өчен территорияләр булдыру мөмкинлеге).

Программаны гамәлгә ашыруда Казан шәһәренең муниципаль берәмлеге генә катнаша.

Муниципаль берәмлек тарафыннан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «ТҮФ» ГХК автоматлаштырылган мәгълүмат системасына кертелгән мәгълүматлар нигезендә гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча муниципаль адреслы программа раслана.

Муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан һәм авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану елы әлеге муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан башка күпфатирлы йортларны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану елы алдыннан килгән күпфатирлы йортлардан, шулай ук җимерелү куркынычы булганда яки гражданнарны закон көченә кергән суд карары нигезендә күчергәндә күпфатирлы йортлардан гражданнар беренче чиратта күчерелергә тиеш. Әгәр төрле елларда авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип танылган берничә күпфатирлы йорт планировка структурасының бер элементы (квартал, микрорайон) яки планировка структурасының чиктәш элементлары чикләрендә урнашкан булса, гражданнарны әлеге йортлардан күчерү авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча адреслы төбәк программасының бер этабы кысаларында гамәлгә ашырылырга мөмкин.

Күчерү этабына кергән күпфатирлы йортлар санын билгеләгәндә, 2024 елга югарыда күрсәтелгән критерийлар һәм финанслау лимитлары исәпкә алынды.

## V. Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү чараларын гамәлгә ашыру өчен финанс чаралары Фонд, Татарстан Республикасы бюджеты һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты акчасы исәбеннән формалаштырыла. Программаны гамәлгә ашыру өчен гомуми чыгымнар барлык финанслау чыганаклары исәбеннән 73 368 159,95 сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:

Фонд – 59 428 209,56 сум (өлеше 81 процент тәшкил итә);

Татарстан Республикасы – 13 206 268,79 сум (өлеше 18 процент тәшкил итә);

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге – 733 681,6 сум (өлеше 1 процент тәшкил итә).

Әлеге акча 2024 елның 1 декабреннән дә соңга калмыйча үзләштерелергә тиеш.

Гражданнарны 2017 елның 1 гыйнварыннан соң авария хәлендә дип танылган авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча, күчерү ысуллары буенча чараларны гамәлгә ашыру планы Программаның 3 нче кушымтасында китерелде.

2024 елга гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү өчен финанс ярдәме күрсәтү акчасын бүлү Программаның 4 нче кушымтасында китерелде.

Казан шәһәрендәге авария хәлендәге торак фондының торак урыннар милекчеләренә башка уңай торак урыннар бирү турындагы суд практикасын игътибарга алып, шулай ук Казан шәһәрендә милекчеләрдән авария хәлендәге торак сатып алу кыйммәтенең югары булуын исәпкә алып, бюджет акчасын экономияләү максатларында Казан шәһәрендә авария хәлендәге торак милекчеләренә аларның ризалыгы белән башка торак урыннарны, алына торган торак урыннар өчен каплау күләмен билгеләгәндә аларның кыйммәте исәбенә кертеп, тәкъдим итәргә планлаштырыла.

Авария хәлендәге торак фондының торак урыннарын алучыларга барлык муниципаль берәмлекләрдә Россия Федерациясе Торак кодексының 89 статьясы нигезендә торак урыннар бирелә.

Программа кысаларында төзелә торган яисә сатып алына торган торакка тәкъдим ителә торган таләпләр Программага 6 нчы кушымтада китерелде.

Фонд акчасы, Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән алынган җирле бюджет акчасы түбәндәгеләргә тотылырга мөмкин:

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 2 өлешенең 2 пунктында күрсәтелгән күпфатирлы йортларда, шулай ук блоклап төзелә торган йортларда (шул исәптән төзелеше тәмамланмаган күпфатирлы йортларда) торак урыннар сатып алу, торак сәясәте һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм гамәлгә ашыру һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен башкаручы федераль башкарма хакимият органы тарафыннан расланган методика нигезендә сайлап алынган проектлар буенча мондый йортларны төзү (мондый йортларны төзү максатларында проект документациясен әзерләүне кертеп), индивидуаль торак йортлар төзү, шулай ук шундый индивидуаль торак йортларны сатып алу, шул исәптән алга таба гражданарга социаль наем шартнамәсе, яки социаль файдаланудагы торак фондының торак урынына наем шартнамәсе, яки авария хәлендәге торак фондыннан күченүгә бәйле рәвештә маневр фондының торак урынына наем шартнамәсе, яки авария хәлендәге торак фондының торак урыны милекчесе белән алышу шартнамәсе буенча торак урыннар бирү максатларында сатып алу;

милкендә авария хәлендәге торак фондына керә торган торак урыннары булган гражданнарга алына торган торак урыннар өчен Россия Федерациясе Торак кодексының 32 статьясындагы 7 өлеше нигезендә өчен түләү.

Программаны өлешчә финанслашу күләме 2024 ел этабы буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 18 процент тәшкил итә.

Программаны гамәлгә ашыру буенча планлаштырыла торган күрсәткечләр Программага теркәлгән 5 нче кушымтада китерелде.

## VI. Программаны гамәлгә ашыру һәм акча тоту барышын мониторинглау һәм контрольдә тоту тәртибе

Программаның җаваплы башкаручысы программа чараларын финанслауны тәэмин итү өчен Фондка заявкалар бирә, Программада катнашучы белән планлаштыруны, үзара хезмәттәшлек итүне, Программа чараларын тормышка ашырганда аның эшчәнлеген координацияләүне һәм тикшерүдә тотуны оештыра.

Программада катнашучы Программа чараларын тормышка ашыру, аларның соңгы нәтиҗәләре, бүлеп бирелә торган финанс чараларыннан максатчан файдалану өчен җавап бирә һәм түбәндәгеләрне тәэмин итә:

гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерүнең муниципаль программасын эшләүне һәм раслауны;

185-ФЗ номерлы Федераль законның $20^{14}$ статьясында каралган финанс ярдәме күрсәтү шартларын үтәүне;

муниципаль берәмлек территориясендә инвентаризация үткәрүне һәм алга таба авария хәлендәге торак фондын мониторинглауны;

күпфатирлы йортлар төзелгән очракта, гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү өчен билгеләнгән йортлар төзелешенә проект документациясен эшләүне;

сатулар үткәрүне һәм күпфатирлы йортлар (блоклы төзелеш йортлары) төзүгә, торак урыннар сатып алуга муниципаль контраклар, торак урыннарны түләп алу шартнамәләре төзүне;

гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерүгә юнәлдерелгән акчаны тоту турында хисаплылык алып баруны һәм аны Программаның җаваплы башкаручысына тәкъдим итүне;

гражданнарны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип танылган торак фондыннан күчерүгә бәйле рәвештә, социаль найм шартнамәсе буенча яки торак урынны милеккә тапшыру турындагы килешү буенча торак урыннар бирүне;

гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерүгә җибәрелгән бюджет акчасыннан файдалануны тикшерүдә тоту.

Программага гомуми җитәкчелек итүне һәм аны тормышка ашыруны тикшерүдә тотуны Программаның җаваплы башкаручысы гамәлгә ашыра, ул билгеләнгән срокларда Фондка Программаны тормышка ашыру барышы һәм Фондның финанс чараларын тоту турында хисап бирә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 12 август, 647 нче карары белән расланган 2024 елга авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча республика адреслы программасына
1 нче кушымта

2024 елга авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча республика адреслы программасының төп чаралары нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары

| Программаны үтәү күрсәткечләре | Үлчәү берәмлеге | Программаны үтәү нәтиҗәсендә ирешелде |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 2024 елга авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча республика адреслы программасын (алга таба – Программа) үтәү нәтиҗәсендә күчерелгән кешеләр саны | кеше | 60 |
| Программага кертелгән авария хәлендәге күпфатирлы йортларда теркәлгән кешеләрнең гомуми санынннан Программаны үтәү кысаларында күчерелгән кешеләр өлеше | процент | 100 |
| Программаны үтәү кысаларында кешеләре күчерелгән бүлмәләр саны | данә | 17 |
| Программаны үтәү кысаларында кешеләре күчерелгән авария хәлендәге күпфатирлы йортлар өлеше | процент | 100 |
| Программаны тормышка ашыру кысаларында торак һәм торак булмаган урыннар буенча аерым күрсәтелгән бушатылган урыннарның гомуми саны (найм, түләп алу һәм алмашу буенча суммада, берәмлек һәм квадрат метрда) | данә | 574,7 кв.метр гомуми мәйданлы 17 бүлмә |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 2017 елның 1 гыйнварыннан соң авария хәлендә һәм эксплуатацияләү барышында физик тузуга бәйле рәвештә сүтелергә тиеш дип танылган барлык авария хәлендәге күпфатирлы йортларга карата Программаны үтәү кысаларында кешеләре күчерелгән авария хәлендәге күпфатирлы йортлар өлеше | процент | 100 |
| «Территорияләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компаниясенең Программаны үтәү өчен Татарстан Республикасына карата акча лимитыннан тотылган акча өлеше | процент | 100 |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 12 август, 647 нче карары белән расланган 2024 елга авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча республика адреслы программасына 2 нче кушымта

2017 елның 1 гыйнварына кадәр авария хәлендә дип танылган күпфатирлы йортлар исемлеге

| Т/с | Муниципаль берәмлек исеме | Адресы | Тибы | Техник торышы | Мәдәни мирас объектларына караву (әйе/юк) | Файдалануга тапшыру елы | Авария хәлендә/ эшкә яраклылыгы чикләнгән дип тану датасы | Күчереп урнаштырылырга тиешле торак фонды турында белешмәләр | | | Граждан-нарны күчерүне тәмамлауның планлаштырыла торган | Йортның төзелеш мәйданы | Йорт өчен җир кишәрлеген формалаштыру турында мәгълүмат | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | мәйданы, кв.метр | кеше саны | гаиләләр саны | датасы | кв.метр | җир кишәрлегенең мәйданы кв.метр | җир кишәрлегенең кадастр номеры | җир кишәрлегенең тасвирнамәсе (бер йортка формалаштырылган, формалаштырылмаган) |
| Барлыгы 2024 елда күчерелергә тиеш | | | X | X | X | X | X | 574,7 | 60 | 17 | X | 0,0 | 2 727,0 | X | X |
| 2024 елга «Территорияләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компаниясе акчасы исәбеннән финанслау каралган күчерү программасы буенча, шул исәптән: | | | X | X | X | X | X | 574,7 | 60 | 17 | X | 0,0 | 2 727,0 | X | X |
| Барлыгы Казан шәһәре | | | X | X | X | X | X | 574,7 | 60 | 17 | X | 0,0 | 2 727,0 | X | X |
| 1. | Казан шәһәре | Казан шәһәре, Гавана ур., 75 нче й. | Күпфатирлы йорт | Авария хәлендә | Юк | 1961 | 25.04.2018 | 242,0 | 15 | 7 | 31.12.2024 | | 796,0 | 16:50:280807:18 | Бер йортка формалаштырылган |
| 2. | Казан шәһәре | Казан ш., Дружный тык., 28 нче й. | Күпфатирлы йорт | Авария хәлендә | Юк | 1980 | 02.04.2018 | 46,3 | 5 | 1 | 31.12.2024 | | | X | Формалаштырылмаган |
| 3. | Казан шәһәре | Казан ш., Дружный тык., 34 нче А йорт | Күпфатирлы йорт | Авария хәлендә | Юк | 1980 | 02.04.2018 | 40,8 | 4 | 1 | 31.12.2024 | | | X | Формалаштырылмаган |
| 4. | Казан шәһәре | Казан шәһәре, Юбилей ур., 3 нче й. | Күпфатирлы йорт | Авария хәлендә | Юк | 1962 | 10.03.2017 | 245,6 | 36 | 8 | 31.12.2024 | | 1 931,0 | 16:50:000000:7292 | Бер йортка формалаштырылган |

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 12 август, 647 нче карары
белән расланган 2024 елга авария
хәлендәге торак фондыннан
гражданнарны күчерү буенча
республика адреслы программасына
3 нче кушымта

Гражданнарны 2017 елның 1 гыйнварыннан соң авария хәлендә дип танылган авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча, күчерү ысуллары буенча чараларны гамәлгә ашыру планы

| Т/с | Муниципаль берәмлек исеме | Барлыгы күчереп урнаштырыла торган торак урыннар мәйданы | Барлыгы күчерү чараларының кыйммәте | Торак урыннар сатып алуга бәйле булмаган күчерү чаралары | | | | | | | | | Торак урыннар сатып алуга (төзүгә) бәйле күчерү буенча чаралар | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | барысы | шул исәптән | | | | | | | | барысы | | | шул исәптән | | | | | | | | | сатып алынган (төзелгән) торак урыннарын алга таба файдалану | | | |
| | | | | | торак урыннар милекчеләренә алына торган торак урыннар өчен түләү һәм субсидияләр бирү | | | | территорияләрне комплекслы үстерү турында шартнамәләр | | буш торак фондка күчерү | ирекле торак фондының торак урыннарын гражданнар даими яшәү өчен яраклы хәлгә китерү | | | | йортлар төзү | | йорт төзүчеләрдән торак урыннар сатып алу | | | | йорт салучылар булмаган затлардан торак урыннар сатып алу | | сатып алынган торак урыннарны гражданнар даими яшәү өчен яраклы хәлгә китерү | социаль наем шартнамәләре буенча бирү | социаль файдаланудагы торак фондына наем шартнамәләре буенча бирү | маневр фондының торак урынына наем шартнамәләре буенча бирү | алышу шартнамәләре буенча бирү |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | төзелә торган йортларда | | файдалануга тапшырылган йортларда | | | | | | | | |
| | | | | күчереп урнаштырыла торган мәйдан | күчереп урнаштырыла торган мәйдан | каплау кыйммәте | торак урыннар сатып алу (төзү) өчен субсидия | заем яки кредиттан файдаланган өчен процентлар түләү чыгымнарының бер өлешен кайтаруга субсидия | күчереп урнаштырыла торган мәйдан | территорияләрне комплекслы үстерү турында шартнамәләр буенча чыгымнарны каплауга яки түләүгә субсидия | күчереп урнаштырыла торган мәйдан | кыйммәте | күчереп урнаштырыла торган мәйдан | сатып алына торган мәйдан | кыйммәте | сатып алына торган мәйдан | кыйммәте | сатып алына торган мәйдан | кыйммәте | сатып алына торган мәйдан | кыйммәте | сатып алына торган мәйдан | кыйммәте | кыйммәте | мәйданы | мәйданы | мәйданы | мәйданы |
| | | кв.метр | сум | кв.метр | кв.метр | сум | сум | сум | кв.метр | сум | кв.метр | сум | кв.метр | кв.метр | сум | кв.метр | сум | кв.метр | сум | кв.метр | сум | кв.метр | сум | сум | кв.метр | кв.метр | кв.метр | кв.метр |
| | «Территорияләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компаниясе акчасы исәбеннән финанслау каралган күчерү программасы буенча барлыгы, шул исәптән: | 574,7 | 73 368 159,95 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 574,7 | 627,26 | 73 368 159,95 | 0,0 | 0,0 | 627,26 | 73 368 159,95 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 285,92 | 0,0 | 0,0 | 341,34 |
| | 2024 ел этабы буенча | 574,7 | 73 368 159,95 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 574,7 | 627,26 | 73 368 159,95 | 0,0 | 0,0 | 627,26 | 73 368 159,95 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 285,92 | 0,0 | 0,0 | 341,34 |
| 1. | Барлыгы Казан шәһәре | 574,7 | 73 368 159,95 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 574,7 | 627,26 | 73 368 159,95 | 0,0 | 0,0 | 627,26 | 73 368 159,95 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 285,92 | 0,0 | 0,0 | 341,34 |

Татарстан Республикасы Министрлар
Кабинетының 2024 ел, 12 август, 647 нче
карары белән расланган 2024 елга авария
хәлендәге торак фондыннан гражданнарны
күчерү буенча республика адреслы
программасына
4 нче кушымта

2017 елның 1 гыйнварыннан соң авария хәлендә дип танылган авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча чаралар планы

| Т/с | Муниципаль берәмлек исеме | Күчерергә планлаштырыла торган кешеләр саны | Күчереп урнаштырыла торган торак урыннар саны | | | Күчереп урнаштырыла торган торак урыннар мәйданы | | | Программаны финанслау чыганаклары | | | | Бюджет акчасын экономияләүнең исәпләпгән суммасы (белешмә өчен) | | | Торак урыннар кыйммәтенең бер өлешен каплау (белешмә өчен) | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | барлыгы | шул исәптән | | барлыгы | шул исәптән | | барлыгы | шул исәптән | | | барлыгы | шул исәптән | | барлыгы | шул исәптән | |
| | | | | гражданнар милке | муниципаль милек | | гражданнар милке | муниципаль милек | | «Территория-ләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компаниясе акчасы исәбеннән | Россия Федерациясе субъекты бюджеты акчасы исәбеннән | җирле бюджет акчасы исәбеннән | | территория-ләрне комплекслы үстерү турындагы карарларны гамәлгә ашыру кысаларында гражданнарны күчерү исәбеннән | гражданнарны буш муниципаль торак фондына күчерү исәбеннән | | торак урыннар милекчеләре акчасы исәбеннән | башка затлар (территорияне комплекслы үстерү турындагы шартнамә буенча инвесторлар) акчасы исәбеннән |
| | | кеше | берәмлек | берәмлек | берәмлек | кв.метр | кв.метр | кв.метр | сум | сум | сум | сум | сум | сум | сум | сум | сум | сум |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 |
| | Барлыгы «Территорияләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компаниясе акчасы исәбеннән финанслау каралган күчерү программасы буенча, шул исәптән: | 60 | 17 | 10 | 7 | 574,7 | 316,7 | 258,0 | 73 368 159,95 | 59 428 209,56 | 13 206 268,79 | 733 681,6 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 |
| | 2024 ел этабы буенча барлыгы | 60 | 17 | 10 | 7 | 574,7 | 316,7 | 258,0 | 73 368 159,95 | 59 428 209,56 | 13 206 268,79 | 733 681,6 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 |
| 1. | Барлыгы Казан шәһәре | 60 | 17 | 10 | 7 | 574,7 | 316,7 | 258,0 | 73 368 159,95 | 59 428 209,56 | 13 206 268,79 | 733 681,6 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 12 август, 647 нче карары белән расланган 2024 елга авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча республика адреслы программасына 5 нче кушымта

2017 елның 1 гыйнварыннан соң авария хәлендә дип танылган авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча төбәк адреслы программаны гамәлгә ашыруның планлаштырыла торган күрсәткечләре

| Т/с | Муниципаль берәмлек исеме | күчереп урнаштырыла торган мәйдан | | Күчереләә торган кешеләр саны | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 2024 ел | барлыгы | 2024 ел | барлыгы |
| | | кв.метр | кв.метр | кеше | кеше |
| | «Территорияләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компаниясе акчасы исәбеннән финанслау каралган күчерү программасы буенча барлыгы, шул исәптән: | 574,7 | 574,7 | 60 | 60 |
| | 2024 ел этабы буенча барлыгы | 574,7 | 574,7 | 60 | 60 |
| 1. | Барлыгы Казан шәһәре | 574,7 | 574,7 | 60 | 60 |

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 12 август, 647 нче
карары белән расланган
2024 елга авария хәлендәге
торак фондыннан граждан-
нарны күчерү буенча респуб-
лика адреслы программасына
6 нчы кушымта

Гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан
күчерү программасы кысаларында төзелә яки сатып алына торган
торакка карата тәкъдим ителә торган
таләпләр

Бу таләпләрне муниципаль заказчылар тарафыннан 2024 елга авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча республика адреслы программасын тормышка ашыру максатларында сатып алулар үткәрү өчен документлар (милекчеләрдән урыннарны түләп алу контрактларыннан һәм файдалануга тапшырылган йортларда төзүчеләр булмаган затлардан торак урыннар сатып алу контрактларыннан тыш) әзерләгәндә исәпкә алырга киңәш ителә.

Файдалануга тапшырылган йортларда йорт төзүчеләр булмаган затлардан торак урыннар сатып алуга контрактлар буенча сатып алына торган торак урыннарга карата таләпләр муниципаль заказчы тарафыннан мөстәкыйль рәвештә билгеләнә.

| Т/с | Таләпнең атамасы | Таләпнең эчтәлеге |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | Йортның проект документациясенә карата таләпләр | Проект документларында параметрларның проект күрсәткечләре һәм торакның башка проект тасвирнамәләре, шулай ук аның куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча проектлана торган чаралар аны төзегәндә һәм файдаланганда гражданнарның (инвалидларны һәм халыкның хәрәкәт итү мөмкинлекләре чикләнгән башка төркемнәрен кертеп) тормышы һәм сәламәтлеге, физик һәм юридик затлар мөлкәте, дәүләт яки муниципаль мөлкәт, әйләнә-тирә мохит өчен куркынычсыз булырлык итеп билгеләнгән булырга тиеш.<br>Проект документлары түбәндәгеләрнең таләпләре нигезендә әзерләнә:<br>«Янгын куркынычсызлыгы таләпләре турында техник регламент» 2008 елның 22 июлендәге 123-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>«Биналарның һәм корылмаларның иминлеге турында |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | | техник регламент» 2009 елның 30 декабрендәге 384-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Проект документациясе бүлекләре составы һәм аларны эчтәлегенә карата таләпләр турында» 2008 елның 16 февралендәге 87 номерлы карары;<br>Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының (алга таба – Россия Төзелеш министрлыгы) 2016 елның 30 декабрендәге 1034/пр номерлы боерыгы белән расланган «Шәһәр төзелеше. Шәһәр һәм авыл җирлекләрен планлаштыру һәм төзү» 42.13330.2016 санитария кагыйдәләре;<br>Россия Төзелеш министрлыгының 2022 елның 13 маендагы 361/пр номерлы боерыгы белән расланган «Күпфатирлы торак биналар 31-01-2003 санитария нормалары һәм кагыйдәләре» 54.13330.2022 санитария кагыйдәләре;<br>Россия Төзелеш министрлыгының 2016 елның 20 октябрендәге 725/пр номерлы боерыгы белән расланган «Бер фатирлы торак йортлар» 55.13330.2016 санитария кагыйдәләре;<br>Россия Төзелеш министрлыгының 2020 елның 30 декабрендәге 904/пр номерлы боерыгы белән расланган «Халыкның аз мобильле төркемнәре өчен биналардан һәм корылмалардан файдалану мөмкинлеге» 59.13330.2020 санитария кагыйдәләре;<br>Россия Төзелеш министрлыгының 2018 елның 24 маендагы 309/пр номерлы боерыгы белән расланган «Сейсмик районнарда төзелеш» 14.13330.2018 санитария кагыйдәләре;<br>Россия Төзелеш министрлыгының 2016 елның 16 декабрендәге 970/пр номерлы боерыгы белән расланган «Биналар һәм корылмалар нигезләре» 22.13330.2016 санитария кагыйдәләре;<br>Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының (алга таба – Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы) 2020 елның 12 мартындагы 151 номерлы боерыгы белән расланган «Янгыннан саклау системалары. Саклау объектларының утка чыдамлылыгын тәэмин итү» 2.13130.2020 санитария кагыйдәләре;<br>Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының 2013 елның 24 апрелендәге 288 номерлы боерыгы |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | | белән расланган «Янгыннан саклау системалары. Саклау объектларында янгын таралуны чикләү. Күләмле-планлаштыру һәм конструктив чишелешләргә карата таләпләр» 4.13130.2013 санитария кагыйдәләре;<br>Россия Төзелеш министрлыгының 2016 елның 24 августындагы 590/пр номерлы боерыгы белән расланган «Биналар һәм корылмалар. Эксплуатация кагыйдәләре. Төп нигезләмәләр» дигән 255.1325800.2016 санитария кагыйдәләре;<br>Россия Төзелеш министрлыгының 2016 елның 3 декабрендәге 891/пр номерлы боерыгы белән расланган «Йөкләнешләр һәм йогынтылар дигән 2.01.07-85* санитария нормалары һәм кагыйдәләре» дигән 20.13330.2016 санитария кагыйдәләре;<br>Россия Төзелеш министрлыгының 2017 елның 27 февралендәге 127/пр номерлы боерыгы белән расланган «Төзелеш конструкцияләрен коррозиядән саклау дигән 2.03.11-85 санитария нормалары һәм кагыйдәләре» дигән 28.13330.2017 санитария кагыйдәләре;<br>Россия Төзелеш министрлыгының 2024 елның 15 маендагы 327/пр номерлы боерыгы белән расланган «Биналарның җылылыгын саклау дигән 23-02-2003 санитария нормалары һәм кагыйдәләре» дигән 50.13330.2024 санитария кагыйдәләре;<br>Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык федераль агентлыгының 2012 елның 25 декабрендәге 109/ГС номерлы боерыгы белән расланган «Тотрыклы һәм киртә конструкцияләр дигән 3.03.01-87 санитария нормалары һәм кагыйдәләре» дигән 70.13330.2012 санитария кагыйдәләре;<br>Россия Төзелеш министрлыгының 2015 елның 8 апрелендәге 261/пр номерлы боерыгы белән расланган «Киртә биналар конструкцияләре. Җылылык-техник төрлелек үзенчәлекләре» дигән 230.1325800.2015 санитария кагыйдәләре;<br>Россия Төзелеш министрлыгының 2016 елның 24 августындагы 590/пр номерлы боерыгы белән расланган «Биналар һәм корылмалар. Эксплуатация кагыйдәләре. Төп нигезләмәләр» дигән 255.1325800.2016 санитария кагыйдәләре;<br>Россия Төзелеш министрлыгының 2023 елның 28 декабрендәге 1015/пр номерлы боерыгы белән раслан- |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | | ган «Салкын килеш бөгелгән цинкланган профильләрдән һәм сырлы калайдан ясалган корыч юка диварлы конструкцияләр. Проектлау кагыйдәләре» дигән 260.1325800.2023 санитария кагыйдәләре;<br>Россия Төзелеш министрлыгының 2017 елның 27 февралендәге 129/пр номерлы боерыгы белән расланган «Агач конструкцияләр дигән II-25-80 санитария нормалары һәм кагыйдәләре» дигән 64.13330.2017 санитария кагыйдәләре;<br>Россия Төзелеш министрлыгының 2017 елның 13 декабрендәге 1660/пр номерлы боерыгы белән расланган «Агач каркаслы бер фатирлы торак биналар. Проектлау һәм төзелеш кагыйдәләре» дигән 352.1325800.2017 санитария кагыйдәләре;<br>Россия Төзелеш министрлыгының 2017 елның 20 декабрендәге 1688/пр номерлы боерыгы белән расланган «Беркетелгән стерженьнәрдә беркетелгән агач конструкцияләр» дигән 382.1325800.2017 санитария кагыйдәләре;<br>Россия Төзелеш министрлыгының 2019 елның 28 октябрендәге 651/пр номерлы боерыгы белән расланган «Агач конструкцияләрне кулланып, күпфатирлы торак биналар. Проектлау кагыйдәләре» дигән 452.1325800.2019 санитария кагыйдәләре;<br>Россия Төзелеш министрлыгының 2022 елның 11 апрелендәге 270/пр номерлы боерыгы белән расланган «Агач бура конструкцияләреннән ясалган биналар. Проектлау һәм төзелеш кагыйдәләре» дигән 516.1325800.2022 санитария кагыйдәләре;<br>Россия Федерациясе Баш дәүләт санитар табибының 2021 елның 28 гыйнварындагы 2 номерлы карары белән расланган «Кеше өчен яшәү тирәлеге факторларының иминлеген һәм (яисә) зарарсызлыгын тәэмин итүгә карата гигиена нормативлары һәм таләпләр» дигән 1.2.3685-21 санитария кагыйдәләре һәм нормалары;<br>Техник җайга салу һәм метрология федераль агентлыгының 2020 елның 23 июнендәге 282-ст номерлы боерыгы белән расланган «Россия Федерациясенең милли стандарты. Төзелеш өчен проект документациясе системасы. Проект һәм эш документларына карата төп таләпләр» дигән 21.101-2020 ГОСТ Р;<br>Россия Төзелеш министрлыгының 2017 елның 26 октябрендәге 1484/пр номерлы боерыгы белән расланган |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | | Проектлана торган капиталь төзелеш объектында кулланыла торган төзелеш материалларын бергә куллануны исәпкә алып, бүлмәнең эчке мохит һавасына химик матдәләрнең җыелма бүлеп чыгарылуын исәпләп чыгару методикасы<br>Төзелергә планлаштырыла торган (төзелә торган) күпфатирлы йортлар, шулай ук сатып алынырга тиешле торак урыннар Россия Федерациясе Баш дәүләт санитария табибының 2021 елның 28 гыйнварындагы 3 номерлы карары белән расланган «Шәһәр һәм авыл җирлекләре территорияләрен тотуга, су объектларына, эчә торган суга һәм халыкны эчә торган су белән тәэмин итүгә, атмосфера һавасына, туфракка, торак урыннарына, җитештерүгә, җәмәгать урыннарыннан файдалануга, санитар-эпидемиягә каршы (профилактик) чараларны оештыруга һәм уздыруга карата санитария-эпидемиология таләпләре» дигән 2.1.3684-21 санитария-эпидемиология кагыйдәләре һәм нормативлары нигезләмәләренә туры килергә тиеш.<br>Күпфатирлы йорт төзү, төзелгән, торак урыннары сатып алына торган күпфатирлы йорт өчен проект документациясенә карата шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнарда билгеләнгән таләпләр нигезендә экспертизаның уңай бәяләмәсе булуны тәэмин итәргә тәкъдим ителә |
| 2. | Төзелә торган күпфатирлы йортны, әзер торак сатып алына торган һәм файдалануга тапшырылган күпфатирлы йортны конструктив, инженерлык һәм технологик яктан тәэмин итүгә карата таләпләр | Төзелә торган йортларда түбәндәгеләр булырга тиеш:<br>түбәндәге материаллардан эшләнгән терәк төзелеш конструкцияләре:<br>а) таш конструкцияләрдән (кирпеч, блоклар), эре тимер-бетон блоклардан, тимер-бетон панельләрдән, тутырылган монолитлы тимер-бетон каркаслардан диварлар;<br>б) җыелма һәм монолитлы тимер-бетон конструкцияләрдән түшәмәләр;<br>в) җыелма һәм монолитлы тимер-бетон һәм таш конструкцияләрдән фундаментлар.<br>Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 нчы бүлегендә каралган проект документациясенә экспертиза бәяләмәсе булганда, күпфатирлы торак биналарны торгызу өчен агач каркас, массив агач панельләр һәм (яисә) беркетелгән конструкцияләр нигезендә завод әзерлеге югары дәрәҗәдәге йортлар комплектларын куллану рөхсәт ителә.<br>Бинаның өске өлешен монолит тимер-бетон һәм (яисә) |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | | эретеп ябыштыру фундаментында төзү өчен, Россия Төзелеш министрлыгының 2021 елның 11 ноябрендәге 817/пр номерлы боерыгы белән расланган авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча төбәк адреслы программаларны формалаштыру буенча методик тәкъдимнамәләргә кушымтаның 1 нче бүлеге таләпләрен үтәү шарты белән җиңел корыч юка диварлы конструкцияләр кулланырга рөхсәт ителә;<br>тиешле ресурслар белән тәэмин итә торган һәм башка оешмалар тарафыннан бирелгән техник шартлар буенча үзәкләштерелгән инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташтыру;<br>санитар узел (аерым яки берләштерелгән), ул фатир эчендәге булырга һәм ваннаны, унитазны, раковинаны үз эченә алырга тиеш;<br>түбәндәге системаларны кертеп, йорт эчендәге инженерлык системалары:<br>а) электр белән тәэмин итү (проект документациясе нигезендә көчле һәм башка электр җиһазлары белән);<br>б) салкын су белән тәэмин итү;<br>в) су чыгару (канализация);<br>г) авария-диспетчерлык хезмәте күрсәтү (проект документациясе нигезендә) мөмкинлеге белән торак бинаның эчке газүткәргечендә газ барышы буенча беренче булып урнаштырылган, тиз арада бикләвеч клапаны белән бикләнә торган, кирәгеннән артык газ чыгу сигнализаторлары урнаштырылган, шулай ук җиңел салдырыла торган тәрәзә блоклары куелган газ белән тәэмин итү (проект документлары нигезендә булган очракта);<br>д) җылылык (үзәкләштерелгән җылыту булмаганда һәм газ булганда, күмәк яисә индивидуаль газ казаннарын урнаштырырга тәкъдим ителә);<br>е) кайнар су белән тәэмин итү;<br>ж) янгын куркынычсызлыгы (проект документациясе нигезендә);<br>з) чүп-чар чыгару (проект документациясе нигезендә булганда);<br>икътисадый максатка яраклы булган очракта, энергия белән тәэмин итүнең локаль системаларын кулланырга тәкъдим ителә;<br>файдалануга кабул ителгән һәм билгеләнгән тәртиптә теркәлгән лифтлар (проект документациясе нигезендә булганда); аларны түбәндәгеләр белән җиһазлау |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | | тәкъдим ителә:<br>а) озатып йөрүче зат белән кресло-коляскадагы инвалидның файдалану мөмкинлеге өчен билгеләнгән кабина;<br>б) диспетчер белән элемтәгә керү өчен җайланма;<br>в) авария булганда, лифт кабинасын яктырту җайланмасы;<br>г) лифт кабинасын ватылмый торган светодиодлы яктырткыч;<br>д) лифт кабинасы ватылмый торган идарә итү панеле;<br>Дәүләт реестрына кертелгән, җитештерүче предприятиеләр тарафыннан тикшерелгән һәм ресурслар белән тәэмин итүче тиешле оешмалар тарафыннан файдалануга кабул ителгән һәм электр җылылык энергиясен, салкын су һәм кайнар суны исәпкә алуның гомумйорт (күмәк) приборларының төгәллеге классларына карата билгеләнгән таләпләргә туры килә торган үлчәү чаралары (билгеләнгән очракларда җылылык белән үзәктән тәэмин иткәндә);<br>йортның энергия нәтиҗәлелеге классына туры китереп, энергия нәтиҗәлелеге класслы пыяла пакетлы тәрәзә блоклары;<br>светодиодлы яктылык җайланмасы белән, ватылмый торган яктырткычлар, хәрәкәт датчиклары һәм яктырткычларны кулланып, йортның катлары арасындагы баскыч мәйданчыкларын яктырту;<br>йорт подъездларына кергәндә светодиодлы яктылык җайланмасы булган һәм ватылмый торган яктырткычларны һәм яктырту датчикларын кулланып яктырту, керү ишеге өстендәге козыреклар, тоткычлары һәм автомат рәвештә ишек ябу җайланмасы булган җылытылган ишек блоклары;<br>йорт подвалына (техник идән астына) кергәндә йозагы, тоткычы һәм автомат рәвештә ишек ябу җайланмасы булган металл ишек блоклары;<br>йортның бөтен периметры буенча ясалган һәм фундаменттан суны читкә җибәрүне тәэмин итә торган арматураланган бетоннан, асфальттан ясалган түшәмә;<br>су агып төшү өчен махсус куелган торба;<br>йорт яны территориясен төзекләндерү, шул исәптән каты катлам, яшелләндерү һәм кече архитектура формалары, төрле билгеләнештәге гомуми кулланылыштагы мәйданчыклар, шул исәптән уен комплексы булган балалар уен мәйданчыгы (проект документлары |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | | нигезендә) |
| 3. | Бүлмәләрне функциональ җиһазландырга һәм эшкәртүгә карата таләпләр | Гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү өчен төзелгән һәм сатып алына торган торак урыннар йортның теләсә кайсы катларында урнашырга (подвал, цоколь, техник, мансардтан башка) тиеш һәм:<br>йорт эчендәге тиешле инженерлык системаларына тоташтырылган фатир эчендәге инженерлык челтәрләре белән җиһазландырылырга тиеш, аның составында түбәндәгеләр (кимендә) булырга тиеш:<br>а) саклау характерындагы сүндерү җайланмалары һәм электр щиты булган электр белән тәэмин итү;<br>б) салкын су белән тәэмин итү;<br>в) кайнар су белән тәэмин итү (үзәкләштерелгән яисә автоном);<br>г) су чыгару (канализация);<br>д) җылылык (үзәкләштерелгән яки автоном);<br>е) вентиляцияләр;<br>ж) авария-диспетчерлык хезмәте күрсәтү (проект документациясе нигезендә) мөмкинлеге белән торак бинаның эчке газүткәргечендә газ барышы буенча беренче булып урнаштырылган, тиз арада бикләвеч клапаны белән бикләнә торган, кирәгеннән артык газ чыгу сигнализаторлары урнаштырылган газ белән тәэмин итү (проект документлары нигезендә булган очракта);<br>в) дәүләт реестрына кертелгән, җитештерүче предприятиеләр тарафыннан тикшерелгән һәм ресурслар белән тәэмин итүче тиешле оешмалар тарафыннан файдалануга кабул ителгән һәм электр энергиясен, салкын су һәм кайнар суны, табигый газны (билгеләнгән очракларда) исәпкә алуның гомумйорт (күмәк) приборларының төгәллеге классларына карата билгеләнгән таләпләргә туры килә торган үлчәү чаралары;<br>чиста һәм төгәлләнгән итеп эшләнелергә тиеш, шул исәптән:<br>а) йозагы, тоткасы һәм карау өчен кечкенә тишеге булган һәм җылытылган керү ишеге;<br>б) йөзлекләре һәм тоткалары булган бүлмә ишекләре;<br>в) йортның энергия нәтиҗәлелеге классына туры китереп, энергия нәтиҗәлелеге класслы пыяла пакетлы тәрәзә блоклары;<br>г) вентиляция рәшәткәләре; |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | | д) фатирның барлык бүлмәләрендә түшәмдәге яктырту приборлары өчен асылмалы элгечләр;<br>е) тиешле фатир эчендәге инженерлык челтәрләренә урнаштырылган һәм тоташтырылган түбәндәге әйберләр:<br>шалтырату сигнализациясе (проект документациясе нигезендә);<br>су кушып болгату җайланмасы һәм сифоны булган юу җиһазы;<br>су кушып болгату җайланмасы һәм сифоны булган юынгыч;<br>утыргычы һәм су агызу багы булган унитаз;<br>су кушып болгату җайланмасы һәм сифоны, җир белән тоташтыру чыбыгы булган ванна;<br>бер, ике клавишлы электр сүндергечләр;<br>электр розеткалары;<br>фатирның барлык бүлмәләрендә электр үткәргечләр һәм патроннар чыгару;<br>газ яки электр плитәсе (проект карары нигезендә);<br>җылылыкны җайга сала торган җылыту радиаторлары (җылылык белән тәэмин итүнең йорт эчендәге системасының җылыту приборлары яисә җылылык кулланыла торган башка элементлары) (проект документациясе нигезендә технологик мөмкинлек булганда), ә автономияле җылыту һәм кайнар су белән тәэмин иткәндә шулай ук ике контурлы котел;<br>ж) ванна бүлмәсе, бәдрәф (берләштерелгән санузел), кладовойлар, балконда (лоджия) бүлмәләрендәге керамик плиткадан торган идәп япмалары, фатирларның калган бүлмәләрендә – тузуга чыдам 22 һәм аннан югары класслы ламинаттан яки кабартылган нигездәге линолеумнан;<br>з) ванна бүлмәсе, бәдрәф (берләштерелгән санитар бүлмә), кладовойлар, аш бүлмәләрендә (аш бүлмәсендәге эш өслегенә тоташып торучы стенаның (стеналарның) бер өлешен һәм ванна бүлмәсендәге керамик плитка белән эшләнгән стенаның (стеналарның) бер өлешеннән тыш) стеналарны су белән эмульсияләнгән яки шуңа охшаш буяулар белән буяу; башка бүлмәләрдә обойлар ябыштыру;<br>и) фатирның барлык бүлмә түшәмнәрен су белән эмульсияләнгән яки башка шуңа охшаш буяу белән буяу йә аңа түшәмә астында металл яки пластик про- |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | | фильгә беркетелгән винил пленкадан (ПВХ) яки җөйсез тукымадан эшләнгән конструкция тарту (тарттырылган түшәмнәр) |
| 4. | Индивидуаль торак йортларның һәм блоклап төзелә торган йортларның конструктив, күләм-планлаштыру һәм башка чишелешләренә карата таләпләр | Индивидуаль торак йортларның, шул исәптән блоклап төзелә торган йорт составына керә торганнарның тасвирнамәләре Россия Төзелеш министрлыгының «Гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү өчен индивидуаль торак йортлар проектларын сайлап алу методикасын раслау турында» 2022 елның 2 августындагы 633/пр номерлы боерыгы нигезендә билгеләнә. |
| 5. | Материалларга һәм җиһазларга карата таләпләр | Йорт төзү проектында заманча сертификацияләнгән төзелеш һәм эшкәртү материаллары, технологик һәм инженерлык җиһазларын куллануны күздә тотарга тәкъдим ителә.<br>Төзелеш торакның проект документациясе таләпләренә туры килүен тәэмин итә торган материаллар һәм җиһазлар кулланып башкарылырга тиеш.<br>Гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү максатларында муниципаль контракт нигезендә торак урыннары сатып алына торган торак йортны төзү барышында башкарыла торган эшләр һәм кулланыла торган төзелеш материаллары, шулай ук мондый эшләрнең нәтиҗәләре техник регламентлар таләпләренә, энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектын кулланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу приборлары белән тәэмин итү таләпләренә туры килергә тиеш |
| 6. | Йортның энергия нәтиҗәлелегенә карата таләп | Россия Төзелеш министрлыгының 2016 елның 6 июнендәге 399/пр номерлы боерыгы белән расланган Энергетика нәтиҗәлелеге классын билгеләү кагыйдәләре нигезендә йортның энергетика нәтиҗәлелеге классын «B» дан да түбәнрәк итеп карамаска тәкъдим ителә. Өйнең энергия нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән түбәндәге чараларны күздә тоту тәкъдим ителә:<br>фатирларда һәм гомуми файдаланудагы урыннарда тәрәзә блокларына карата югарыда күрсәтеп үтелгән өстәмә таләпләр куярга;<br>күпфатирлы йортларда гомуми файдаланудагы биналарда, баскыч мәйданчыкларында, подъезд ишекләре алдында хәрәкәт һәм яктылык датчиклары белән светодиодлы яктырткычлар куярга; |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | | светодиодлы яктырткычларны һәм яктырту датчикларын кулланып, күпфатирлы йортларның йорт янындагы территорияне яктыртырга;<br>подвал (цоколь) һәм чорма түшәмәләренең җылылык изоляциясен (проект документлары нигезендә) булдырырга;<br>проект документациясендә каралган кайнар һәм салкын су белән тәэмин итүне, электр энергиясен, газ һәм башкаларны исәпкә алу приборларын куярга;<br>терморегуляторлар белән җылылык радиаторларын урнаштырырга (проект документациясе нигезендә технологик мөмкинлек булганда);<br>йорт подъездларына җылытылган һәм автомат рәвештә ябыла торган җайланмасы булган керү ишекләрен урнаштырырга;<br>йорт подъездларының стенасы җылытылган керү тамбурларын эшләргә, автомат рәвештә ябыла торган җайланмалы, җылытылган тамбур (керә һәм үтә торган) ишекләрен куярга.<br>Йорт фасадында Россия Төзелеш министрлыгының 2016 елның 6 июнендәге 399/боерыгы белән расланган Күпфатирлы йортларның энергетика нәтиҗәлелеге классларын билгеләү кагыйдәләренең III бүлеге нигезендә йортның энергетика нәтиҗәлелеге классы күрсәткече булуын тәэмин итәргә. |
| 7. | Йортның аннан файдалану документларына карата таләпләр | Җитештерүче предприятиеләрнең механик, электр, санитар-техник һәм башка җайланмаларга (лифт җайланмасын кертеп), энергетика ресурсларын куллануны исәпкә алу приборларына (гомумйорт (күмәк) һәм индивидуаль) һәм энергетика ресурсларын бирү белән идарә итү узелларына һ.б. паспортлар һәм алардан файдалану инструкцияләре, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 13 августындагы 491 номерлы карары белән расланган Күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәтне карап тоту кагыйдәләренең 24 һәм 26 пунктларында каралган тиешле документлар (документларның күчермәләре) (федераль законнар таләпләре һәм «Биналар һәм корылмалар. Файдалану кагыйдәләре. Гомуми нигезләмәләр» дигән 255.1325800.2016 нигезендә эшләнгән күпфатирлы йортны файдалану буенча инструкцияне кертеп) булу.<br>Фатир эчендәге инженерлык җиһазларыннан файда- |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | | лану буенча инструкцияләр булу. Фатир эчендәге инженерлык җиһазларыннан файдалану буенча инструкцияләр комплекты заказчыга тапшырылырга тиеш. |